# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№1 28 ноябрь 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге составына керүче Мәлбагыш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында.

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Уставы нигезендә 2021 елның 28 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гарażданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Сез 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Мәлбагыш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Мәлбагыш авылында юлларны кардан чистарту(килешү буенча түләү);
- җәйге чорда Мәлбагыш авылында үлән чабу, территорияне җыештыру буенча хезмәтләр (килешү буенча эшләр өчен түләү, триммер өчен запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
- Мәлбагыш авылында "Авыл бәйрәме" , «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Халыкара инвалидлар көне», «Яңа ел», «Җиңү көне» бәйрәмнәрен оештыру һәм үткәрү;
- Мәлбагыш авылында спорт чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк һәм сувенир продукция сатып алу);
- халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту, килешү буенча эшләр өчен түләү, материаллар, җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларны алыштыру, эчә торган суны биохимик һәм бактериологик анализлау;

- Мәлбагыш авылында урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (электр товарлары сатып алу, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 354 гражданнар жыенында катнашучы теркәлгән, гражданнар җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 184

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 184, «КАРШЫ» » позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Мәлбагыш торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. Түбәнәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

«Сез 2022 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, Азнакай муниципаль районы Мәлбагыш авыл җирлеге Мәлбагыш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Мәлбагыш авылында юлларны кардан чистарту(килешү буенча түләү);
- җәйге чорда Мәлбагыш авылында үлән чабу, территорияне җыештыру буенча хезмәтләр (килешү буенча эшләр өчен түләү, триммер өчен запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
- Мәлбагыш авылында "Авыл бәйрәме" , «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Халыкара инвалидлар көне», «Яңа ел», «Җиңү көне» бәйрәмнәрен оештыру һәм үткәрү;
- Мәлбагыш авылында спорт чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк һәм сувенир продукция сатып алу);
- халыкны су белән тәэмин итүне, ташландык суларны агызуны оештыру (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту, килешү буенча эшләр өчен түләү, материаллар, җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларны алыштыру, эчә торган суны биохимик һәм бактериологик анализлау;
- Мәлбагыш авылында урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (электр товарлары сатып алу, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү)

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Мәлбагыш авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәлбагыш авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Мәлбагыш авыл җирлеге башлыгы А.Й.Әхмәтшин